УДК 7.01:94

# КЕРӘШЕННӘРНЕҢ БАШ КИЕМНӘРЕ

***Хабибуллина Э.Р.***
*«В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

Традиция – ул милләтнең рухи һәм хезмәт тәҗрибәсен буыннан буынга тапшыру төре. Кием-салым ягыннан керәшен татарларының хәзерге киемнәре татар халкының башка төркемнәреннән аерылмый. Әмма өлкән буын кешеләре арасында әле үзләре сугып теккән, борынгыдан килә торган үрнәкләр белән бизәлгән киемнәрне очратырга мөмкин. Гомумән, керәшеннәр үзләре суккан тукымалардан теккән киемнәрне әле соңгы елларга кадәр кигәннәр, фабрика товарларын сирәк кешеләрдә генә күрергә мөмкин булган. Үзләре сугып, үзләре теккән күлмәкләрне кайберәүләр әле хәзер дә кадерләп сандык төпләрендә саклыйлар һәм бәйрәм, туй вакытларында киеп тә йөриләр.

**Ачкыч сүзләр:** керәшеннәр, кием-салым, баш киемнәре.

Кием-салымнар арасында сакланып калган борынгы киемнәрдән иң күзгә ташланганы – баш киемнәре. Үзенчәлекләр, күбрәк хатын-кыз баш киемнәрендә чагыла. Кызларның баш киемнәре яшь киленнәрнекеннән һәм өлкән хатын-кызларныкыннан аерылып тора.

## Калпак

***Ак калпак, калпак*** – ак мамык җептән озын итеп бәйләнә, очында чугы да була. Яшь кызлар башларына калфак киеп, аның өстеннән ***укачачак*** бәйләгәннәр. Ак калфак татар халкында элек киң таралган баш киеме булган. Ул кулланылыштан күптән түгел генә төшеп калган. Чистай, Минзәлә, Алабуга өязләре керәшеннәрендә әле XX йөз башларында да ак калфаклар кигәннәр.

Хәзерге вакытта керәшен татарларында ак калфаклар сакланмаган, әмма Казан арты төбәгендә, Мишә буе авылларында керәшен кызлары әле илленче елларга кадәр кичке уеннарга чигүле калфаклар киеп чыкканнар. Халык җырларында исә «ак калпак» сүзе дә еш кулланыла:

*Эзәй буйларыннан эз киткән,*
*Ак калпакай кигән кыз киткән.*

*Ак калпакайы сызмалы,*
*Без Йакты Күл (ав. ис.) кызлары.*
*Ак калпагың кисәнә,*
*Чугын артка чөй сәнә.*
*Эчеңдәге җаның ничек,*
*Безне шулай күрсәнә (борынгы җыр).*

## Такыйа, такийа

***Такыйа, такийа*** – кызлар баш киеме, аны Лаеш районы Ташкирмән авылында яшәүче керәшеннәр һәм тау ягы керәшеннәре әле дә хәтерлиләр, сөйләп күрсәтәләр. Такыя, кызлар баш киеме буларак, элекке вакытларда татар халкының барлык төркемнәрендә дә булган, шулай ук башка төрки халыкларда һәм угро-фин халыкларында кызлар баш киеме буларак билгеле. Чувашларда тухъя – кызлар баш киеме, такыя, тухъя – башкортларда һәм Идел буе угрофин халыкларында: мари, удмурт, бисермәннәрдә, ягъни төрки халыклар белән элек-электән аралашып яшәгән күршеләрдә дә кызлар кия торган баш киеме такыя дип аталган.

Такыя – баш киеме мәгънәсендә әдәби әсәрләрдә дә кулланыла: *Хәтфә калфаклар, чигелгән кәләпүшләр, укалы такыялар – һәммәсе Казаннан килеп, Мәскәүдә сатыладыр.*

## Кашбау

***Кашбау*** – очлы итеп тегелгән баш киеме. Аның аскы өлешенә эрерәк, ә өскә таба ваграк тәңкәләр тезелгән була. Мисал: Балык тәңкәсе күwек җалтырап тора кашбау тәңкәсе. Кашбау>каш+бау сүзләреннән ясалган, ягъни каш өстенә кадәр төшеп тора торган бизәнү әйбере. Мондый баш киеме электә Казан татарларында киң таралган булган. Шулай ук татар-мишәрләрнең ләмбрә (кашпау) һәм темников (кашбау) төркемнәрендә, башкортларда (кашмау) һәм чувашларда (хушпу), бисермәннәрдә (кашпу) дә бар. Димәк, кашбау кайчандыр Идел буе төрки халыкларында киң таралган баш киеме булган дип нәтиҗә ясарга нигез бар.

***Кашбау, кашмау*** сүзләре әдәби әсәрләрдә, язучылар телендә:

*Зәңгәр күлдә яшел төнбоек,*

*Чәчкәсеннән кашбау ишәрмен (М.Җәлил).*

*«Карчык... вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын... олы кызы Сылубикәгә билгеләп тора» (Ә.Еники).*

## Баш бәйләү

Яшь киленнәрнең баш киемнәре икенчерәк төрле булган. Туй вакытында «баш бәйләтү» дигән йоланы башкарганда, яшь киленнең кыз чакта кия торган баш киемнәрен салдырып, киленнәр кия торган баш киемнәрен киерткәннәр.

Керәшеннәрдә бу эшне кыйаматлык әни башкара торган булган. Кызлар баш киеме: ***калпак-чачак, маңгай укаларны*** салдырып, хатыннар баш киеме: ***мәләнчек, сүрәкә, чигәчә*** һ.б. киертелгән. Бу йола Идел буендагы күрше халыклар, мәсәлән, мари, чуваш, удмуртларда, шулай ук кайбер төрки халыкларда да билгеле. Борынгы славяннар турындагы язмаларда да бу турыда мәгълүматлар күп.

*Кыйаматлыкка баргач баш бәйләтәләр. Элгәре моңа шулай буладырыйы. Мәләнчек, чигәчә, сүрәкә, түгәрәк җаулык бәйләтә кыйаматлык.*

***Мәләнчек*** – тәңкәле һәм укалы һәртөрле баш киемнәре астына киеп калдырала торган чепчик формасындагы баш киеме. Мисал: *Мәләнчек кийеп, баш бәйләп куй, чәчләр күренеп тормасын.* Казан арты керәшеннәрдә бу сүзнең ***мәләчлек/мәрәчлек*** вариантлары кулланыла.

***Чигәчә*** – чигә+чә, чигә турысына тәңкәләр тезелгән баш киеме. Чигәчәсе матур буган, тәңкәләр йалтырап тора. Кызыл бәйгүчле ди чигәчәсен. Казан арты керәшеннәре сөйләшендә чигәчә сүзе урынына җилкәлек сүзе кулланыла.

***Сүрәкә*** – мәләнчек һәм чигәчә өстеннән киелә торган баш киеме. Ул укалар белән чигеп, биек итеп тегелгән була. Тантаналы вакыйгалар (бәйрәм, туй һ.б.) уңае белән гадәттә олы яшьтәге хатын-кызлар кигәннәр. Сүрәкә чигүчеләр авылда кадерле һәм дәрәҗәле кешеләр булып исәпләнгәннәр.

Сүрәкә сүзе халык җырларында да еш кулланыла:

*Сүрәкәләр чиктем киргесез,*
*Киреп чиккәннәргә биргесез.*
*Сайлап җарне мин сөймәдем,*
*Сайлап сөйгәннәргә биргесез.*
*Сүрәкәләр чиктем бизәкләп,*
*Дүрт ти почмакайын пичәтләп.*
*Әйтәсе сүземне әйтми калдым,*
*Алдагы көнемне исәпләп.*

***Сүрәкә канаты*** – сүрәкәнең арткы ягына беркетелеп, аркага төшеп тора, кулдан сугып эшләнгән яки ефәк материядән тегелгән була. Ул Алабуга районы керәшеннәрендә ***чукул*** дип атала.

*Сүрәкә канаты артка асылынган, ычы итәкле буладырыйы, кыругум җаннары тасмалы буладырыйы. Аның эстеннән катыннар җаулыгы бәйли җәш киленнәр, чуклы ак җа*улык – чст. крш.

Керәшеннәрдәге ***сүрәкә*** формасында булган баш киеме русларда сорока һәм мариларда (сорака) бар. Бу баш киеме һәм аны белдерә торган сүз төрки халыкларда башка бәйли торган урама, яулык мәгънәсенә туры килә торган борынгы сүзләр: сарук, саруг, сарик, сарги формаларыннан үзгәртелеп рус һәм угро-фин телләренә кереп киткән дигән фикерләр бар.

***Чукул*** – сурәкә, маңгай ука һәм маңгай тәңкәнең арткы өлешенә беркетелгән материя, Алабуга районы керәшеннәрендә шулай атала. Ул арканы каплап тора, очына, гадәттә, челтәр тотылган була. Мисал: *Чукулы җепәктән теккән Дарҗаның, анықыя сорагыз*. Казан арты, Чистай керәшеннәрдә шул ук мәгънәдә ***сүрәкә канаты*** дигән сүз кулланыла.

Башкортстанның Шаран районы Базгыя авылында шундый ук мәгънәдә ***качмык*** сүзен кулланалар: *Качмык сәленеп тора аркада, бәк матур булаларыйы кызлар элгәре.*

## Яулык һәм бөркәнчекләр

Хәзерге вакытта хатын-кызларның баш киемнәреннән почмаклап бәйләгән яулык төп кулланылышта тора. Электә исә хатын кыз баш киемнәре, кием булу белән бергә, күп төрле детальләрдән торган үзенчәлекле бизәнү әйберләре та хезмәт иткән.

***Түгәрәк җаулык*** – кара ефәк җеп белән чигелгән, кырыйларына ука тотылган, маңгай турысына тәңкәләр тезеп эшләнгән баш киеме. Аны яшь киленнәр кия. Түгәрәк яулык дип аталса да, бу баш киеме дүрт почмаклы, аның уртасына күпертеп чигелгән эре кара бизәкләр төшерелгән, тикшерүче галимнәр күрсәткәнчә, шундый бизәкләр болгар-хазар берлегенә караган төрки халыклар өчен хас билге булып торган. Яшь киленнәргә мәләнчек, сүрәкә, чигәчә киертелгәннән соң, өстән шушы түгәрәк яулыкны бөркәндерәләр.

*Түгәрәк җаулык тектем мин,*
*Түгәрәк күзем түнтәреп.*
*Син икәнен белгән булсам,*
*Карарыйм күземне күтәреп.*

*Түгәрәк җаулыкны бер җыл җаптым җәш килен бугачын. Түгәрәк җаулык чиктем мин* – каз. ар. крш. *Түгәрәк җаулыкны зур кан'ишле кешеләр, җәш киленнәр җаба торган булган. Безнең әни бер җыл җаптым дийер ийе. Кайсы кеше ике ай гына җаба* – чст. крш.

***Ак җаулык*** – олырак хатын-кызлар бәйли торган баш киеме. Ак яулык дип аталса да, аның ике башы күпертеп чигелгән, сөлгесыман итеп сугылган озын ак тукымадан ясалган, аны иң өстән чалмасыман итеп чорнап куйганнар. Керәшеннәрдәге ак җаулык, формасы һәм чигү үрнәкләре, ягыннан, чувашлардагы сурпан тутри һәм пус тутри дигән баш киеменә бик охшаш.

Чистай керәшеннәрендә шундый баш киеме катыннар җаулыгы дип атала һәм аның формасы да икенчерәк төрле: *Катыннар җаулыгы чуклы була.*

***Дарай җаулык*** – өстән бөркәнә торган чәчәкле ефәк яулык. Ул гадәттә кызыл төстәге ефәктән була. Мәсәлән: *Марҗыйның сөйгән җегете дарай җаулык бүләк итеп биргән.* Дарай сүзе башка төрки халыкларда да ефәк мәгънәсен белдерә: ногай телендә даьрйе – ефәк шәл, кумык телендә дарай – тафта, дарай челек – тафта күлмәк.

***Тастар җаулык*** – яшь киленнәр бөркәнә торган яулык (Тау ягы керәшеннәрендә).

*Тастар җаулык эшләгән алты атна, үзе сугып, башларын те-геп (чигеп) нәгышлаган.*

***Күшәгә*** – киндердән тегелгән бизәкле яулык. Ул сүз казан арты төбәгендә, төньяк районнарда: Балтач, Малмыж керәшеннәре сөйләшендә очрый.

***Кәбинәт җаулык, кәминәт җаулык*** – чәчәкле ефәк яулык, аны кәбенгә кергәндә бөркәнгәннәр.

## Бөркәнчек

***Бөркәнчек*** – аны туйда яшь киленнәр бөркәнә, ак киндердән яки кызыл шакмаклы алачадан тегелгән була (кызыл бөркәнчек дип тә әйтәләр).

*Имәннәр сайгак җимерек,*
*Җүкәләр сайгак җимерек.*
*Атлар җигеп, бөркәнчек салып,*
*Кыз алырга килдек җилдереп.*

Бү сүз тау ягы керәшеннәрендә (бөркәнчек), касыйм татарлары сөйләшендә (бер 'инче'), себер татарларының түбән сөйләшендә

(пөргәнцек), чуваш телендә (пургенчек) дә шул ук мәгънәдә кулланыла. Борынгы төрки телдә бүркөншүк, бүрүнчүк формаларына кулланылган. Туйларда бөркәнчек ачу дигән махсус йола башкарылган.

Җәйнең матур көннәрендә чат башларында, су буйларында, ямьле болыннарда оештырыла торган түгәрәк уеннарына, май чабу, питырау, тройсын бәйрәмнәренә керәшен хатын-кызлары озын итеп тегелгән калталы (бәбәй итәкле) күлмәкләр киеп, алмалап сугылган яки чигелгән алъяпкычлар бәйләп, башларына тәңкәләр тезеп эшләнгән һәм ука-җепләр белән чигелгән баш киемнәре кийеп чыкканнар. Хәзерге көннәрдә кайбер кешеләрдә генә күреп була торган бу борынгы киемнәрне үткән гомерләрнең, әбиләрнең һәм әниләрнең истәлеге итеп, кадерләп сакларга кирәк. Яшь буынга, ул киемнәрнең исемнәрен әйтеп, киеп күрсәтү үзе генә дә ни тора.

Без керәшен халкының гамәли бизәлеш сәнгате, төрле чигү ысуллары белән тагын да якынрак таныштык. Төрле милли бәйрәмнәр үткәргәндә, туйларда, дини йолалар вакытында бу костюмнар хәзер дә һәрдаим киелеп тора. Күп очракта ул киемнәр тәңкәләр тезеп һәм укалар белән чигеп бизәлгән. Кием-салымнары, тәңкәле бизәнү әйберләренең формасы ягыннан керәшен татарлары киемнәре Идел буендагы күрше халыклар – удмуртлар һәм чувашлар белән якын тора, ләкин ул киемнәрнең атамалары – борынгыдан килгән төрки-татар сүзләре.

## Чыганаклар һәм әдәбият

1. *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан: Матбугат йорты, 1997. 248 б.

2. *Макаров Н.В.* Без бер тамырдан. Мәктәпләр өчен уку ярдәмлеге. Казан. «Мәгариф», 2002.

**Автор турында мәгълүмат:**

**Хабибуллина Эльмира Рәсим кызы** – татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Осиново авылында «В.В.Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе (Осиново авылы, Россия Федерациясе); e-mail: vicavicas01@gmail.com

**Хабибуллина Э.Р.** Керәшеннәрнең баш киемнәре

## ГОЛОВНЫЕ УБОРЫ КРЯШЕН

Традиция – это форма передачи духовного опыта народа из поколения в поколение. По одежде современная одежда кряшен не отличается от одежды других групп татарского населения. Однако среди людей старшего поколения все еще можно найти одежду, изготовленную своими руками, украшенную старинными узорами. В целом крестьяне до последних лет носили одежду собственного изготовления, а фабричные изделия редко можно было увидеть на публике. Некоторые люди до сих пор дорожат платьями, которые они сшили сами, хранят их в своих гардеробах и носят во время праздников и свадеб.

**Ключевые слова:** кряшены, одежда, головные уборы.

**Сведения об авторе:**
**Хабибуллина Эльмира Расимовна** – учитель татарского языка и литературы МБОУ «Лицей имени В.В. Карпова» села Осиново Зеленодольского района Республики Татарстан (с.Осиново, Российская Федерация); e-mail: vicavicas01@gmail.com

## KRYASHEN HATS

Tradition is a form of transferring the spiritual experience of a people from generation to generation. In terms of clothing, modern Kryashen clothing does not differ from the clothing of other groups of the Tatar population. However, among the older generation you can still find handmade clothes decorated with ancient patterns. In general, peasants wore their own clothes until recent years, and factory-made items were rarely seen in public. Some people still treasure the dresses they made themselves, keeping them in their wardrobes and wearing them during holidays and weddings.

**Keywords:** Kryashens, clothes, hats.

**About the author:**
**Khabibullina Elmira Rasimovna** – Teacher of Tatar language and Literature, Lyceum named after V.V. Karpov of the Osinovo village of the Zelenodolsk district of the Republic of Tatarstan (Osinovo village, Russian Federation); e-mail: vicavicas01@gmail.com